

Торле газета битләрендә (Атюрьево, Саранск, Темниково һәм башкаларында) авылларда яшәvче балаларны, хәтта олылырны да даими рәвештә сукбай этләр куркыта, дип хәбәрлиләр. Аларны кем кvзәтергә тиеш сон?

Ни очен хайваннар хужасыз? Кагыйдә буларак, эт балалары һәм мәчеләр ташлана. Йорт хайваннарыннан аларнын "яраксызлыгы" аркасында да арыналар. Тик кешеләрнен каты могамәләсе нәтижәсендә урамнарда янадан-яна койрыклы сукбайлар пәйда булуы кvнелләрне рәнжетә. Без барыбыз да авыл халкы, унайлы һәм имин яшәргә телибез. Әмма сукбай хайваннарга каршы корәш проблемасы бик четерекле һәм торле. Халык арасында сукбай этләргә каршы кискен корәш чараларынын ачык битарафлары да, әлеге дvрт аяклы дусларны яклаучылары да бар. Һәр якнын да vз дореслеге, бәхәссез дәлилләре бар.
Сукбай этләр һәр торак пунктта диярлек бар. Хужасыз этләр урамнарда һәм паркларда халыкка юл бирми куркыталар. Еш кына олкәннәр генә тvгел, балалар да урам жыелмаларынын һожvменә дучар ителә (хужасыз этләр Темниковта бер баланын курткасын ерткалаганнар), ә бала курыккач, кайчагында, гомер буена кала. Тешләv очраклары да сирәк кvренеш тvгел. Әгәр берни дә кабул итмәсән, сукбай этләр артачак һәм vтеп баручыларны талауларын дәвам итәчәкләр. Шуна кvрә якын арада районнарда сукбай хайваннарны тоту буенча акция vткәреләчәк.
Без тагын бер кат халыкка морәжәгать итәбез: проблема, нигездә, терлекләрдә тvгел, ә бездә, кешеләрдә бит. "Безнен кечкенә туганнарыбызны" урамга чыгарудан туктагач кына, бу кvренеш белән мәнгегә хушлашырга була. Сукбай этләр безгә кvктән тошмәде бит.
Белгәнебезчә, кvп еллар элек Конбатыш Европа һәм АКШ илләрендә закон тарафыннан йорт хайваннарын мәжбvри чиплау практикасына кертелде. Әгәр анын йорт хайваны урамда икән, анын хужасынын координатларын бик тиз билгеләргә була, ветеринария полициясе моны катгый кvзәтә һәм гаеплеләрне зур штраф белән жәзалый. Сонышнан язылган хакыйкатьне тагын бер кат искә тошереп vтәсе килә: "Без ияләштергәннәр очен жаваплы". Ойгә яки ишегалдына хайван алырга уйласагыз, керткәнче йоз тапкыр чамалагыз. Чонки сез аны вакытка гына тvгел, ә ботен гомеренә аласыз, ә бу 10 ел һәм аннан да кvбрәк булырга момкин. Аларны ашатырга, дәваларга, яратырга кирәк булачак.

Наилә Насырова